| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 03.05.2023 | г. Казань | № 55-1/нпс-2023 |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында төзелгән идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулыкка максималь чик бәяләрне билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2023 елның 3 маендагы 16-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында төзелгән идарә итүче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулыкка максималь чик бәяләрне билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь чик бәяләр әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең «Гражданнарга, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның торакка ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында төзелгән идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш кооперативларына яисә башка

махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулыкка (утынга) чик дәрәҗәдә максималь ваклап сату бәяләрен билгеләү турында» 2011 елның 7 октябрендәге 9-1/нпс номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.05.2023 № 55-1/нпс-2023
карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында төзелгән идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш кооперативларына яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулыкка максималь чик бәяләр

| Ягулыкның исеме | Үлчәү берәмлеге | Сату шартлары | Өстәмә хак салымы белән ваклап сату бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| Каты ягулык | тыгыз куб. м | франко-диләнке | 386 |
| | тыгыз куб. м | 10 км ераклыкка китерүне исәпкә алып, франко-склад, шул исәптән: | 642 |
| | тыгыз куб. м | франко-склад | 547 |
| | тыгыз куб. м | 10 километрга китерү | 95 |

Искәрмәләр:

1. Ягулыкның максималь чик бәяләре 1 тыгыз куб метр өчен сумнарда билгеләнгән. Әгәр җайга салынулы оешма исәпкә алуны склад чараларында алып бара икән, әлеге карар белән билгеләнгән бәяләр Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының «Урманны санитар кисү һәм тәрбияви кисү вакытында башкарыла торган эшләрнең тармакара нормаларын һәм вакытын раслау турында» 1995 елның 19 сентябрендәге 53 номерлы карары белән расланган күчерү коэффициентларын кулланып күчерелә ала.

2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 148 пункты нигезендә каты ягулыкны транспортка төяү кулланучыдан өстәмә түләү алмыйча башкарыла.  Кулланучыга җиткерелгән каты ягулыкны бушату өстәмә түләү хисабына башкарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге